РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШИКШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422053, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Шикши, ул. Школьная, 4
тел. (84362) 46-1-35

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕКШЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422053, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шекше авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт
тел. (84362) 46-1-35

e-mail:Shik.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
27.11.2024

КАРАР
№ 31

Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.01.2022 ел, №1 карары белән расланган торак урыннарына мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында " 15.08.2022 №1415 карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Башкарма комитетының «Торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында " 25.01.2022 ел, №1 карары белән расланган торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Төзелгән гаризаны формат-логик тикшерү гаризаның электрон рәвешендәге һәр кырын тутыру барышында орган билгели торган таләпләр нигезендә бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал гаризаның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»;

1.2. 2.6.1 пунктының 10), 15), 17), 18) пунктчаларында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shikshi адресы буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Шекше авыл җирлеге Башлыгы Р.Р. Хәйртдинов